ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 гыйнвар 2025 ел № 11

Башкарма комитетның 2022 елның 22 августындагы 4260 номерлы Карары белән расланган спорт судьясы квалификация категориясе бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Спорт судьялары турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 28 февралендәге 134 номерлы Боерыгы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 22 августындагы 4260 номерлы Карары белән расланган спорт судьясы квалификация категориясе бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.4.1 пунктта «биш эш көне» сүзләрен «16 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2.5.1 пунктта сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- региональ спорт федерациясе, исемлеккә кертелгән физкультура-спорт оешмасы, федераль орган бүлекчәсе җитәкчесенең яки вәкаләтле вазыйфаи затының яки вазыйфаи затының мөһере (булган очракта) һәм имзасы белән таныкланган исәпләү карточкасының күчермәсе;»;

3) 2.5.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«икенче категорияле спорт судьясы» спорт судьясы квалификация категориясен бирү өчен «Россиянең халыкара класслы спорт мастеры» яки «Россиянең спорт мастеры» таныклыгының күчермәсе (булган очракта).»

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ